**Исполнительный комитет Карашай Сакловского сельского поселения Сармановского муниципального района Республики Татарстан.**
**423378 ул.Ленина д.100 с.Карашай Саклово Телефон: 885559 4-92-18**

**ИНН 1636005581 КПП 163601001**
**ОГРН 1061687003070**
**ОКАТО 92253828000**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай Саклау авыл жирлеге башкарма комитеты**
**423378 ,Карашай Саклау авылы, Ленин ур.100 йорты Телефон: 885559 4-92-18**

**ИНН 1636005581 КПП 163601001**
**ОГРН 1061687003070**
**ОКАТО 92253828000**

КАРАР № 62
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы

2018 елның 19 июне

Советның 2007 елның 18 июлендәге 11 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы нигезендә карар итте:

1. 9.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   "9.4. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлауларда катнашучыларны җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәргәндә торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин."
2. 9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   "9.5. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер ай һәм өч айдан артыграк була алмый.
3. 11.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   "11.2. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының

норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер айдан һәм өч айдан артыграк була алмый."

4. 12.2 пунктта «Комиссия» сүзен «Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар оештыручы» сүзләренә алмаштырырга, «биру мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар» сүзләрен «биру турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы В.В.Хосниева